**СОВЕТ**

**МАСАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423753, д. Масады,ул.Нефтяников,д.18

Тел. 3-44-49

e-mail: akt.masad.akt@yand

**АКТАНЫШ**

**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**МЭСЭДЕ АВЫЛ**

**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423753, Мэсэде авылы Нефтяниклар ур.,18нче йорт.

Тел. 3-44-49

e-mail: akt.masad.akt@yandex.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**6 июнь 2024 ел** **№ 11**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пунктына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы, «Төбәк салымнары суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Физик затларның җирле салымнары суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Мәсәде авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

Совет рәисе Мингазов Ф.Ф.

Совет Масадинского сельского поселения Актанышского муниципального района Республики Татарстан
ОГРН 1021600558008
ИНН 1604003454